РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.09.2023 Кукмара ш. № 501

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан агросәнәгать комплексын һәм бюджет өлкәсе учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итүгә ярдәм итү өчен акча бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә, яшь белгечләрне агросәнәгать комплексына һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының бюджет өлкәсе учреждениеләренә эшкә җәлеп итү максатыннан **карар бирәм:**

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы агросәнәгать комплексын һәм бюджет өлкәсе учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итүгә ярдәм итү өчен Кукмара муниципаль районы бюджетыннан акча бирү тәртибе турында нигезләмә (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының бюджет ярдәмен алучыларны билгеләү буенча район комиссиясе составы (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет житәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 07.09.2023 елның 501 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы агросәнәгать комплексын һәм бюджет өлкәсе учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итүгә ярдәм итү өчен Кукмара муниципаль районы бюджетыннан акча бирү тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы агросәнәгать комплексын һәм бюджет өлкәсе учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итүгә ярдәм итү өчен Кукмара муниципаль районы бюджетыннан акча бирү тәртибе механизмын билгели.

2. Акчалар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты турында карарда каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет акчаларының баш идарәчесенә – әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчаларын алучы буларак Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Муниципаль ярдәм Кукмара муниципаль районының авыл хуҗалыгы оешмаларында яки муниципаль бюджет өлкәсе учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә, югары белем бирү оешмаларын һәм һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаганнан соң, муниципаль ярдәм күрсәтү турында карар кабул ителгәнче 15 эш көненнән артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килү шарты белән күрсәтелә:

- Россия Федерациясе гражданнары;

- муниципаль ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән вакытта яшь белгечнең яше 35 яшькә кадәр;

- Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары юк;

- аларга карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә банкротлык процедурасы кертелмәгән.

4. Югары белемле яки урта һөнәри белемле, эшкә алынган, авыл хуҗалыгы оешмаларында яки муниципаль бюджет өлкәсе учреждениеләрендә кимендә биш ел эшләргә үз өсләренә Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган форма буенча килешүдә (алга таба – килешү) каралган бурычны алган яшь белгечләргә түбәндәгеләр бирелә: Кукмара муниципаль районы авыл җирлекләрендә (Зур Кукмара һәм Манзарас авыл җирлекләреннән тыш)

эшләүче белгечләр өчен – 300,0 мең сум, Манзарас, Зур Кукмара авыл җирлекләрендә һәм Кукмара шәһәрендә эшләүче белгечләр өчен - 200,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Бер тапкыр бирелә торган түләүне (алга таба – түләүне) бирү өчен нигез булып, авыл хуҗалыгы оешмаларын һәм муниципаль бюджет өлкәсе учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итүгә муниципаль ярдәм комиссиясе (алга таба – комиссия) карары һәм Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, Мәгариф идарәсе, Мәдәният идарәсе һәм Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе (алга таба – Идарәләр) тарафыннан Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырылган бер тапкыр бирелергә тиеш булган түләүләр турында алучылар киселешендә белешмә-хисаплар тора. Ярдәм алучылар киселешендә исемлек югарыда күрсәтелгән Идарәләр тарафыннан кадрлар белән тәэмин итүгә муниципаль ярдәм комиссиясенә бирелә.

Комиссиянең эш регламенты һәм аның составы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

5. Түләүнең бирүнең максаты – авыл хуҗалыгы җитештерүендә, бюджет өлкәсе учреждениеләрендә һөнәрләрнең абруен күтәрү һәм югары белем бирү оешмаларын, һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаганнан соң, авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм муниципаль бюджет өлкәсе учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә ярдәм итү.

6. Бер тапкыр бирелә торган түләү торак бина (фатир, торак йорт) сатып алганда яки шәхси торак йорт төзегәндә беренчел кертемне түләү өчен бирелә.

Авыл хуҗалыгы оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү шарты булып эш бирүче белән бюджеттан бирелә торган бер тапкыр бирелә торган ярдәмнең 50% күләмендә өстәмә финанс ярдәме күрсәтү турында килешү булу тора.

7. Түләүләр алу өчен яшь белгеч (алга таба – гариза бирүче) эшкә урнашканнан соң күп дигәндә алты ай эчендә Идарәләргә түбәндәге документларны тапшыра:

түләүләр бирү турында гариза (ирекле форма), ул шул исәптән Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә гариза бирүчегә карата банкротлык процедурасы кертелмәгәнлеге турында мәгълүматны үз эченә ала;

- авыл хуҗалыгы оешмасы яки муниципаль бюджет өлкәсе учреждениесе белән төзелгән хезмәт шартнамәсе күчермәсе;

- гариза бирүченең шәхесен раслый торган документ күчермәсе;

- эшкә кабул итү турында боерыкның күчермәсе;

- кушымта белән белем турында диплом күчермәсе (дипломга кушымта);

- хезмәт кенәгәсенең тиешенчә расланган күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат;

- хәрби бурычлылар өчен хәрби билетның күчермәсе;

- салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) тарафыннан Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлар үтәлеше турында салым органы белешмәсе;

- эш бирүче белән бюджеттан бирелә торган бер тапкыр бирелә торган ярдәмнең 50% күләмендә өстәмә финанс ярдәме күрсәтү турында килешүнең күчермәсе (авыл хуҗалыгы оешмаларында эшләүче яшь белгечләр өчен).

Түләүләр алу өчен Идарәләргә тапшырыла торган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы оешмасы яки муниципаль бюджет өлкәсе учреждениеләре тарафыннан раслана.

8. Идарәләр түбәндәгеләрне башкаралар:

- түләүләр турында гаризаларны алар кабул ителгән көнне махсус журналда теркәп баралар;

- түләүләр бирү турында гариза теркәлгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көнлек срокта тәкъдим ителгән документларның әлеге Нигезләмәнең 3 пунктына туры килүен карыйлар һәм комиссиягә карауга тапшыралар;

- түләүләр бирү турында Карар кабул ителгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә, гариза бирүче белән килешү төзиләр;

- килешү төзелгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә җыелма белешмә – гариза бирүчеләргә түләүләрне күчерү өчен хисап төзиләр;

- белешмә – хисап төзелгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә аны Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрәләр.

Түләүләрне бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

- гариза бирүченең түләүләр алу өчен кабат мөрәҗәгать итүе;

- документлар тапшырмау (тулы булмаган күләмдә тапшыру) һәм (яки) алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

- алучы тапшырган мәгълүматның дөрес булмавы;

- алучының әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве.

Түләүләр бирүдән баш тарткан очракта,әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта Идарәләр гариза бирүчегә, тиешле нигезләрне күрсәтеп, түләүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрәләр.

Кирәк булганда, Идарәләр гариза бирүче белән Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзиләр.

9. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты бюджет акчаларының баш бүлүчесе булып тора һәм, тиешле субсидияләр турында алучылар киселешендә җыелма белешмәләр – хисаплар тапшырылганнан

алып, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә үзенең шәхси хисабыннан, субсидия алучыларның кредит оешмаларында ачылган шәхси хисапларына акчаларны күчерүне гамәлгә ашыра.

10. Яшь белгеч һәм авыл хуҗалыгы оешмасы яки муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан төзелгән хезмәт килешүе биш еллык срок тәмамланганчы туктатылган очракта (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 8 пунктында, 81 статьясындагы беренче өлешенең 1,2 һәм 4 пунктларында, 83 статьясындагы беренче өлешенең 1, 2, 5-7 пунктларында каралган нигезләр буенча хезмәт килешүе туктатылган очраклардан тыш), яшь белгеч хезмәт килешүе туктатылган көннән исәпләнгән бер тапкыр бирелә торган түләүнең бер өлешен эшләнмәгән чорга пропорциональ рәвештә Кукмара районы муниципаль бюджеты кеременә хезмәт килешүе туктатылган көннән алып 30 көн эчендә кире кайтара.

Бер тапкыр бирелә торган түләүнең бер өлешен кайтару срогын бозган очракта, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетыәлеге Положениенең 10 пунктында билгеләнгән срок тәмамланганнан соң, эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаларны Кукмара муниципаль районы бюджетына законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

11. Бюджет акчаларын куллануны контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 07.09.2023 елның 501 номерлы карарына 2 нче кушымта

Авыл хуҗалыгы оешмаларын һәм муниципаль бюджет өлкәсе учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итүгә муниципаль ярдәм комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Гарифуллин А.Х. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Хәнәфина Ч.Г. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Хәкимова Р.Т. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенең баш белгече, комиссия секретаре; |
| Комиссия әгъзалары | |
| Гаянова Р.Н. | Кукмара муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |
| Әхмәдуллин Р.Н. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Әхмәтшина А.М. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Минһаҗева Р.З. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе, комиссия секретаре; |
| Сәмигуллин И.К. | Кукмара муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Мусина Р.Р. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районында социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Иванов В.К. | «Татарстан Республикасы ветераннар (пенсионерлар) оешмасының республика Советы» белән хезмәттәшлек буенча консультант. |